**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Экологический кодекс Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
6 июня 2024 года

**Статья 1**

Внести в Экологический кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I), № 44 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 54 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 57 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 57 (часть I), № 83 (часть I); 2023, № 27 (часть I), № 35 (часть I), № 48 (часть I), № 56 (часть I), № 81 (часть I), № 86 (часть I); 2024, № 16 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 2:
а) абзац двадцать седьмой признать утратившим силу;
б) в абзаце сорок третьем слова «общественных объединений и некоммерческих организаций, юридических и физических лиц» заменить словами «общественных объединений и других негосударственных некоммерческих организаций, иных юридических лиц, граждан»;
в) в абзаце семидесятом слова «экологическим требованиям, установленным техническими регламентами и законодательством в области охраны окружающей среды,» заменить словами «требованиям в области охраны окружающей среды»;

2) в статье 3:
а) в абзаце восьмом слово «надзора» заменить словами «контроля (надзора)»;
б) в абзаце шестнадцатом слова «общественных объединений и некоммерческих организаций, юридических и физических лиц» заменить словами

«общественных объединений и других негосударственных некоммерческих организаций, иных юридических лиц, граждан»;

в) абзац двадцать третий изложить в следующей редакции:

«участие общественных объединений и других негосударственных некоммерческих организаций, иных юридических лиц, граждан в решении задач охраны окружающей среды;»;

3) в части 1 статьи 8:

а) в абзаце шестом слово «надзору» заменить словами «контролю (надзору)»;

б) в абзаце седьмом слово «надзор» заменить словами «контроль (надзор)»;

в) в абзаце девятом слово «надзору» заменить словами «контролю (надзору)»;

г) в абзаце тринадцатом слово «надзору» заменить словами «контролю (надзору)»;

д) в абзаце тридцать седьмом слово «надзору» заменить словами «контролю (надзору)»;

4) наименование раздела III изложить в следующей редакции:

«РАЗДЕЛ III

**ПРАВА И ОБЯЗАННОСТИ ГРАЖДАН, ОБЩЕСТВЕННЫХ ОБЪЕДИНЕНИЙ И ДРУГИХ НЕГОСУДАРСТВЕННЫХ НЕКОММЕРЧЕСКИХ ОРГАНИЗАЦИЙ В ЭКОЛОГИЧЕСКОЙ СФЕРЕ**»;

5) в части 2 статьи 10:

а) в абзаце втором слова «общественные объединения и иные некоммерческие организации» заменить словами «общественные объединения и другие негосударственные некоммерческие организации»;

б) абзац четвертый дополнить словами «, а также принимать участие в общественных обсуждениях при проведении оценки воздействия на окружающую среду»;

6) в статье 11:

а) в наименовании слова «общественных объединений и некоммерческих организаций» заменить словами «общественных объединений и других негосударственных некоммерческих организаций»;

б) в части 1:

в абзаце первом слова «Общественные объединения и некоммерческие организации» заменить словами «Общественные объединения и другие негосударственные некоммерческие организации»;

абзац седьмой дополнить словами «, в том числе участвовать в общественных обсуждениях при проведении оценки воздействия на окружающую среду»;

дополнить новым абзацем тринадцатым следующего содержания:

«предъявлять в суд иски о возмещении вреда, причиненного окружающей среде вследствие нарушений обязательных требований;»;

абзац тринадцатый считать абзацем четырнадцатым;

в) в части 2 слова «Общественные объединения и некоммерческие организации» заменить словами «Общественные объединения и другие негосударственные некоммерческие организации»;

7) в части 1 статьи 12 слова «общественным объединениям и некоммерческим организациям» заменить словами «общественным объединениям и другим негосударственным некоммерческим организациям»;

8) статью 31 изложить в следующей редакции:

«Статья 31. **Проведение оценки воздействия на окружающую среду**

Оценка воздействия на окружающую среду проводится в отношении планируемой хозяйственной и иной деятельности, которая может оказать прямое или косвенное воздействие на окружающую среду, в соответствии с Федеральным законом от 10 января 2002 года № 7-ФЗ «Об охране окружающей среды».»;

9) в части 3 статьи 33 слова «в порядке, установленном федеральным законодательством» заменить словами «в соответствии с федеральным законодательством»;

10) статью 34 признать утратившей силу;

11) статью 36 изложить в следующей редакции:

«Статья 36. **Эксперт государственной экологической экспертизы объектов регионального уровня**

1. Экспертом государственной экологической экспертизы является специалист, обладающий научными и (или) практическими познаниями по рассматриваемому вопросу, аттестованный в установленном порядке и привлеченный в соответствии с федеральным законом уполномоченным исполнительным органом государственной власти Республики Татарстан в области экологической экспертизы к проведению государственной экологической экспертизы по соответствующим направлениям науки, техники, технологии.
2. Аттестация эксперта государственной экологической экспертизы осуществляется в соответствии с федеральным законом.
3. Экспертом государственной экологической экспертизы не может быть представитель заказчика документов и (или) документации, подлежащих государственной экологической экспертизе, или разработчика объекта государственной экологической экспертизы, гражданин, состоящий в трудовых или иных договорных отношениях с указанным заказчиком или разработчиком объекта государственной экологической экспертизы, а также представитель юридического лица, состоящего с указанным заказчиком или разработчиком объекта государственной экологической экспертизы в таких договорных отношениях.

4. Эксперт государственной экологической экспертизы участвует в ее проведении в соответствии с федеральным законом и заданием, выданным уполномоченным исполнительным органом государственной власти Республики Татарстан в области экологической экспертизы.

5. Эксперт государственной экологической экспертизы при проведении государственной экологической экспертизы имеет право:

1) заявлять уполномоченному исполнительному органу государственной власти Республики Татарстан в области экологической экспертизы о необходимости представления заказчиком документов и (или) документации на государственную экологическую экспертизу дополнительных материалов для всесторонней и объективной оценки объектов государственной экологической экспертизы;

2) формулировать особое мнение об объекте государственной экологической экспертизы, которое прилагается к заключению государственной экологической экспертизы.

6. Эксперт государственной экологической экспертизы обязан:

1) осуществлять всесторонний, полный, объективный и комплексный анализ представляемых на государственную экологическую экспертизу документов и (или) документации с учетом передовых достижений отечественной и зарубежной науки и техники, определять их соответствие требованиям в области охраны окружающей среды и предоставлять заключения по таким документам и (или) документации;

2) соблюдать требования законодательства об экологической экспертизе;

3) соблюдать установленные в соответствии с федеральным законом порядок и сроки осуществления государственной экологической экспертизы;

4) обеспечивать объективность и обоснованность выводов своего заключения по объекту экологической экспертизы;

5) участвовать в подготовке материалов, обосновывающих учет при проведении государственной экологической экспертизы заключения общественной экологической экспертизы, замечаний по объекту государственной экологической экспертизы, поступивших в ходе общественных обсуждений объекта государственной экологической экспертизы, а также поступивших от органов местного самоуправления, общественных объединений и других некоммерческих организаций, граждан аргументированных предложений по экологическим аспектам хозяйственной и иной деятельности, которая подлежит государственной экологической экспертизе;

6) давать на заседаниях экспертной комиссии государственной экологической экспертизы разъяснения заказчику документов и (или) документации в отношении имеющихся замечаний к представленным на государственную экологическую экспертизу документам и (или) документации;

7) обеспечивать сохранность документов и (или) документации и конфиденциальность сведений, представленных на государственную экологическую экспертизу.

7. Оплата труда внештатных экспертов государственной экологической экспертизы производится уполномоченным исполнительным органом

государственной власти Республики Татарстан в области экологической экспертизы на договорной (контрактной) основе в соответствии с федеральным законом.

8. Оплата труда штатных сотрудников, участвующих в проведении государственной экологической экспертизы, производится в установленном законодательством Российской Федерации порядке.»;

12) в статье 38:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Заключением государственной экологической экспертизы является документ, подготовленный экспертной комиссией государственной экологической экспертизы и одобренный не менее чем двумя третями ее списочного состава, содержащий обоснованные выводы о соответствии документов и (или) документации, обосновывающих намечаемую в связи с реализацией объекта экологической экспертизы хозяйственную и иную деятельность, требованиям в области охраны окружающей среды. Состав и содержание заключения государственной экологической экспертизы устанавливаются в соответствии с федеральным законом.»;

б) часть 5 изложить в следующей редакции:

«5. Положительное заключение государственной экологической экспертизы теряет юридическую силу в случаях, установленных федеральным законом.»;

13) в абзаце четвертом статьи 40 слова «и общественным организациям (объединениям)» заменить словами «, общественным объединениям и другим негосударственным некоммерческим организациям»;

14) статью 41 изложить в следующей редакции:

«Статья 41. **Общественная экологическая экспертиза**

1. Общественная экологическая экспертиза организуется и проводится в порядке, установленном федеральным законом, по инициативе граждан, общественных объединений и других негосударственных некоммерческих организаций, а также по инициативе органов местного самоуправления общественными объединениями и другими негосударственными некоммерческими организациями.

2. Не вправе инициировать и проводить общественную экологическую экспертизу общественные объединения и другие негосударственные некоммерческие организации, а также граждане:

1) признанные иностранными агентами в соответствии с Федеральным законом от 14 июля 2022 года № 255-ФЗ «О контроле за деятельностью лиц, находящихся под иностранным влиянием»;

2) лишенные в судебном порядке специального права, права занимать должности в области охраны окружающей среды и природопользования;

3) признанные недееспособными;

4) имеющие гражданство иностранного государства.»;

15) статью 48 изложить в следующей редакции:
«Статья 48. **Общественный экологический контроль**

1. Общественный экологический контроль осуществляется в целях реализации прав граждан в области охраны окружающей среды, а также предотвращения и выявления нарушений законодательства в области охраны окружающей среды.
2. Общественный экологический контроль осуществляется общественными объединениями и другими негосударственными некоммерческими организациями, а также гражданами.
3. Проведение общественного экологического контроля на объектах, используемых для обеспечения обороны страны и безопасности государства, других объектах, сведения о которых составляют государственную тайну, не допускается.
4. Результаты общественного экологического контроля, представленные в органы государственной власти Российской Федерации, органы государственной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления, подлежат обязательному рассмотрению в порядке, установленном законодательством.»;

16) в части 1 статьи 49 слово «надзора» заменить словами «контроля (надзора)»;

17) в абзаце шестом статьи 69 слова «музеи, библиотеки, учреждения культуры, природоохранные учреждения, организации спорта и туризма» заменить словами «общественные объединения и другие негосударственные некоммерческие организации, иные юридические лица, граждан»;

18) в абзаце первом части 2 статьи 73 слова «общественными объединениями, средствами массовой информации, а также организациями, осуществляющими образовательную деятельность, учреждениями культуры, музеями, библиотеками, природоохранными учреждениями, организациями спорта и туризма, иными юридическими лицами» заменить словами «средствами массовой информации, общественными объединениями и другими негосударственными некоммерческими организациями, иными юридическими лицами, гражданами»;

19) в части 2 статьи 94 слово «скотомогильники» заменить словами «объекты уничтожения биологических отходов»;

20) в статье 98:
а) в пункте 2 части 13 слово «скотомогильников» заменить словами «объектов уничтожения биологических отходов»;
б) часть 16 изложить в следующей редакции:
«16. Установление границ водоохранных зон и границ прибрежных защитных полос водных объектов, включая обозначение на местности посредством специальных информационных знаков на территориях, используемых для

рекреационных целей (туризма, физической культуры и спорта, организации отдыха и укрепления здоровья граждан, в том числе организации отдыха детей и их оздоровления), осуществляется в порядке, установленном в соответствии с федеральным законодательством Правительством Российской Федерации.»;

21) статью 100 изложить в следующей редакции:

«Статья 100. **Зоны чрезвычайных ситуаций на водных объектах, предотвращение негативного воздействия вод и ликвидация его последствий**

1. В соответствии с законодательством в области охраны окружающей среды и законодательством в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций зонами чрезвычайных ситуаций могут объявляться водные объекты и речные бассейны, в которых в результате техногенных и природных явлений происходят изменения, представляющие угрозу здоровью или жизни человека, объектам животного и растительного мира, другим объектам окружающей среды.

2. При угрозе возникновения чрезвычайной ситуации или при возникновении чрезвычайной ситуации в соответствии с законодательством в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций использование поверхностных водных объектов для восстановления пропускной способности русел рек осуществляется без предоставления водных объектов в пользование.

3. По решению органа местного самоуправления городского или сельского поселения, муниципального района, городского округа, по решению уполномоченного Кабинетом Министров Республики Татарстан органа исполнительной власти Республики Татарстан при угрозе возникновения чрезвычайной ситуации или при возникновении чрезвычайной ситуации в соответствии с законодательством в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций донный грунт может быть использован, в том числе в случаях, предусмотренных законодательством в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций, при условии, что донный грунт не содержит твердых полезных ископаемых, не относящихся к общераспространенным полезным ископаемым.

4. Порядок осуществления деятельности по восстановлению пропускной способности русел рек, использования извлеченного донного грунта при угрозе возникновения чрезвычайной ситуации или при возникновении чрезвычайной ситуации в соответствии с законодательством в области защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций устанавливается в соответствии с федеральным законодательством Правительством Российской Федерации.

5. В целях предотвращения негативного воздействия вод на определенные территории и объекты и ликвидации его последствий осуществляются предусмотренные статьей $67^1$ Водного кодекса Российской Федерации мероприятия по предотвращению негативного воздействия вод и ликвидации его последствий.

6. Указанные в части 5 настоящей статьи мероприятия осуществляются в рамках водохозяйственных мероприятий, предусмотренных статьей $7^1$ Водного кодекса Российской Федерации.»;

22) наименование статьи 120 изложить в следующей редакции:
«Статья 120. **Федеральный государственный лесной контроль (надзор)**»;

23) в части 1 статьи $135^3$ слова «, который предоставляет данные указанного государственного охотхозяйственного реестра уполномоченному федеральному органу исполнительной власти» заменить словами «с использованием государственной информационной системы управления в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов»;

24) в части 6 статьи 165 слова «курортных, лечебно-оздоровительных, рекреационных зон» заменить словами «рекреационных зон, округов санитарной (горно-санитарной) охраны природных лечебных ресурсов».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Подпункты «а» и «б» пункта 1, подпункты «б» и «в» пункта 2, пункт 4, подпункт «а» пункта 5, подпункт «а», абзац второй подпункта «б» и подпункт «в» пункта 6, пункты 7, 15, 17 и 18 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 июля 2024 года.

3. Подпункт «в» пункта 1, подпункт «а» пункта 2, пункт 3, подпункт «б» пункта 5, абзац третий подпункта «б» пункта 6, подпункт «а» пункта 12, пункты 13, 14, 16, 21 и 24 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2024 года.

4. Пункты 8, 11, 19 и 20 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 марта 2025 года.

5. Пункт 23 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 сентября 2025 года.

6. Положения статьи 36 Экологического кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) в части привлечения к проведению государственной экологической экспертизы аттестованных в установленном порядке экспертов применяются с 1 сентября 2025 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
18 июня 2024 года
№ 51-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) егерме җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) кырык өченче абзацта «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның, юридик һәм физик затларның» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларның, башка юридик затларның, гражданнарның» сүзләренә алмаштырырга;

в) җитмешенче абзацта «техник регламентлар һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар белән билгеләнгән экологик таләпләргә» сүзләрен «әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) сигезенче абзацта «күзәтчелегенең» сүзен «контроленең (күзәтчелегенең)» сүзләренә алмаштырырга;

б) уналтынчы абзацта «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның, юридик һәм физик затларның» сүзләрен «иҗтимагый

берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларның, башка юридик затларның, гражданнарның» сүзләренә алмаштырырга;

в) егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау бурычларын хәл итүдә иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларның, башка юридик затларның, гражданнарның катнашуы;»;

3) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) алтынчы абзацта «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацта «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

г) унөченче абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

д) утыз җиденче абзацта «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

4) III кисәкнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III КИСӘК
**ЭКОЛОГИЯ ӨЛКӘСЕНДӘ ГРАЖДАННАРНЫҢ, ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРНЕҢ ҺӘМ ДӘҮЛӘТНЕКЕ БУЛМАГАН КОММЕРЦИЯГӘ КАРАМАГАН БҮТӘН ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**»;

5) 10 статьяның 2 өлешендә:

а) икенче абзацта «иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацка «, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү уздырганда җәмәгать фикер алышуларында катнашырга» сүзләрен өстәргә;

6) 11 статьяда:

а) исемдә «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм коммерциягә карамаган оешмаларның» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «Иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацка «, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү уздырганда җәмәгать фикер алышуларында катнашырга» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

«мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны түләттерү турында судка дәгъва белдерергә;»;

унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга;

в) 2 өлештә «Иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «Иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 12 статьяның 1 өлешендә «иҗтимагый берләшмәләргә һәм коммерциягә карамаган оешмаларга» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләргә һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

8) 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31 статья. **Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыру**

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү әйләнә-тирә мохиткә турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясарга мөмкин булган планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә карата «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә уздырыла.»;

9) 33 статьяның 3 өлешендә «федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «федераль законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

10) 34 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 36 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36 статья. **Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экология экспертизасы эксперты**

1. Карала торган мәсьәлә буенча фәнни һәм (яисә) практик белемнәре булган, билгеләнгән тәртиптә аттестация үткән һәм фәннең, техниканың, технологиянең тиешле юнәлешләре буенча дәүләт экология экспертизасын уздыруга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы тарафыннан федераль закон нигезендә җәлеп ителгән белгеч дәүләт экология экспертизасы эксперты була.

2. Дәүләт экология экспертизасы экспертына аттестация федераль закон нигезендә үткәрелә.

3. Дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле документлар һәм (яисә) документация заказчысының яисә дәүләт экология экспертизасы объектын эшләүченең вәкиле, күрсәтелгән заказчы белән яисә дәүләт экология экспертизасы объектын эшләүче белән хезмәт яисә башка шартнамәчел мөнәсәбәтләрдә торучы граждан, шулай ук күрсәтелгән заказчы белән яисә дәүләт экология экспертизасы объектын эшләүче белән шундый шартнамәчел мөнәсәбәтләрдә торучы юридик затның вәкиле дәүләт экология экспертизасы эксперты була алмый.

4. Дәүләт экология экспертизасы эксперты аны уздыруда федераль закон һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы тарафыннан бирелгән йөкләмә нигезендә катнаша.

5. Дәүләт экология экспертизасы эксперты дәүләт экология экспертизасын уздырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендә вәкаләтле башкарма органына дәүләт экология экспертизасына документлар һәм (яисә) документация заказчысы тарафыннан дәүләт экология экспертизасы объектларын һәрьяклап һәм объектив бәяләү өчен өстәмә материаллар бирү зарурлыгы турында мөрәҗәгать итәргә;

2) дәүләт экология экспертизасы объекты турында аерым фикер белдерергә, ул дәүләт экология экспертизасының бәяләмәсенә кушып бирелә.

6. Дәүләт экология экспертизасы эксперты түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

1) дәүләт экология экспертизасына тапшырыла торган документларга һәм (яисә) документациягә, илдә һәм чит илләрдә фән һәм техника өлкәсендә алдынгы казанышларны исәпкә алып, һәрьяклап, тулы, объектив һәм комплекслы анализ ясарга, аларның әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә туры килүен билгеләргә һәм шундый документлар һәм (яисә) документация буенча бәяләмәләр бирергә;

2) экология экспертизасы турындагы законнар таләпләрен үтәргә;

3) дәүләт экология экспертизасын гамәлгә ашыруның федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртибен һәм срокларын үтәргә;

4) экология экспертизасы объекты буенча үз бәяләмәсе нәтиҗәләренең объективлылыгын һәм нигезләнгән булуын тәэмин итәргә;

5) дәүләт экология экспертизасын уздырганда иҗтимагый экология экспертизасы бәяләмәсен, дәүләт экология экспертизасы объекты турында фикер алышулар барышында кергән дәүләт экология экспертизасы объекты буенча искәрмәләрне, шулай ук дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экология аспектлары буенча җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм коммерциягә карамаган бүтән оешмалардан, гражданнардан кергән дәлилләнгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны нигезли торган материаллар әзерләүдә катнашырга;

6) дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе утырышларында документлар һәм (яисә) документация заказчысына дәүләт экология экспертизасына тапшырылган документларга һәм (яисә) документациягә карата булган искәрмәләргә аңлатмалар бирергә;

7) дәүләт экология экспертизасына тапшырылган документларның һәм (яисә) документациянең сакланышын һәм белешмәләрнең конфиденциальлеген тәэмин итәргә.

7. Дәүләт экология экспертизасының штаттан тыш экспертлары хезмәтенә түләү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы тарафыннан шартнамә (контракт) нигезендә федераль законга таянып башкарыла.

8. Дәүләт экология экспертизасын уздыруда катнашучы штаттагы хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»;

12) 38 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт экология экспертизасының эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән һәм аның исемлек составының кимендә өчтән икесе тарафыннан хупланган, экология экспертизасы объектын реализацияләүгә бәйле рәвештә ниятләнә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезләүче документларның һәм (яисә) документациянең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләргә туры килү-килмәве турындагы нигезләнгән нәтиҗәләр кергән документ дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе була. Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе составы һәм эчтәлеге федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе федераль законда билгеләнгән очракларда юридик көчен югалта.»;

13) 40 статьяның дүртенче абзацында «һәм экология экспертизасы уздыруны оештыручы иҗтимагый оешмаларга (берләшмәләргә)» сүзләрен «, экология экспертизасы уздыруны оештыручы иҗтимагый берләшмәләргә һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

14) 41 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«41 статья. **Иҗтимагый экология экспертизасы**

1. Иҗтимагый экология экспертизасы гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар инициативасы буенча, шулай ук җирле үзидарә органнары инициативасы буенча иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар тарафыннан федераль законда билгеләнгән тәртиптә оештырыла һәм үткәрелә.

2. Түбәндәге иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар, шулай ук гражданнар иҗтимагый экология экспертизасы уздыру турындагы тәкъдим белән чыгарга һәм аны уздырырга хокуксыз:

1) «Чит илләр йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агентлары дип танылган;

2) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә суд тәртибендә махсус хокуктан, вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм ителгән;

3) эшкә сәләтсез дип танылган;

4) чит дәүләт гражданлыгы булган.»;

15) 48 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«48 статья. **Иҗтимагый экология контроле**

1. Иҗтимагый экология контроле әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозуны кисәтү һәм ачыклау максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Иҗтимагый экология контроле иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар, шулай ук гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен файдаланыла торган объектларда, белешмәләре дәүләт серен тәшкил иткән башка объектларда иҗтимагый экология контролен уздыру рөхсәт ителми.

4. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына тапшырылган иҗтимагый экология контроле нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә һичшиксез каралырга тиеш.»;

16) 49 статьяның 1 өлешендә «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

17) 69 статьяның алтынчы абзацында «музейлар, китапханәләр, мәдәният учреждениеләре, табигатьне саклау учреждениеләре, спорт һәм туристлык оешмалары» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар, башка юридик затлар, гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

18) 73 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацында «иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, мәдәният учреждениеләре, музейлар, китапханәләр, табигатьне саклау учреждениеләре, спорт һәм туризм оешмалары, башка юридик затлар» сүзләрен «массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган бүтән оешмалар, башка юридик затлар, гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

19) 94 статьяның 2 өлешендә «хайваннарның үләт базларын» сүзләрен «биологик калдыкларны юкка чыгару объектларын» сүзләренә алмаштырырга;

20) 98 статьяда:

а) 13 өлешнең 2 пунктында «үләт базлары» сүзләрен «биологик калдыкларны юкка чыгару объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 16 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү, рекреацион (туризм, физик культура һәм спорт, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту, шул исәптән балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру) максатларда файдаланыла торган территорияләрдә махсус мәгълүмат тамгалары кую юлы белән урында билгеләүне

дә кертеп, федераль законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

21) 100 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«100 статья. **Су объектларында гадәттән тыш хәлләр зоналары, суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү**

1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә гадәттән тыш хәлләр зоналары дип техноген һәм табигый күренешләр аркасында кешенең сәламәтлегенә яисә гомеренә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларына, башка әйләнә-тирә мохит объектларына куркыныч яный торган үзгәрешләр бара торган су объектлары, шулай ук елга бассейннары игълан ителергә мөмкин.

2. Гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы янаганда яисә гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә елгаларның үзәннәре аша су агу мөмкинлеген торгызу өчен җир өсте су объектларыннан файдалану су объектларын файдалануга тапшырмыйча гына гамәлгә ашырыла.

3. Гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы янаганда яисә гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә шәһәр яисә авыл җирлегенең, муниципаль районның, шәһәр округының җирле үзидарә органы карары, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән органы карары буенча, су төбе грунты составына гомумтаралган файдалы казылмаларга карамаган каты файдалы казылмалар кермәгәндә, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә, шул исәптән халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарда каралган очракларда, су төбе грунтыннан файдаланырга мөмкин.

4. Гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы янаганда яисә гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар нигезендә елгаларның үзәннәре аша су агу мөмкинлеген торгызу эшчәнлеген гамәлгә ашыру, су төбеннән чыгарылган грунттан файдалану тәртибе федераль законнар нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

5. Суларның аерым территорияләргә һәм объектларга тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү максатларында суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе Су кодексының $67^1$ статьясында каралган чаралар гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән чаралар Россия Федерациясе Су кодексының $7^1$ статьясында каралган суга кагылышлы хуҗалык гамәлләре кысаларында гамәлгә ашырыла.»;

22) 120 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«120 статья. **Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге)**»;

23) $135^{3}$ статьяның 1 өлешендә «аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әлеге дәүләт аучылык хуҗалыгы реестры күрсәткечләрен вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына тапшыручы вәкаләтле органы тарафыннан» сүзләрен «, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә идарә итүнең дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

24) 165 статьяның 6 өлешендә «курорт, дәвалау-савыктыру, рекреацион зоналар» сүзләрен «рекреацион зоналар, табигый дәвалау ресурсларының санитария (тау-санитария) саклау округлары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары, 2 пунктының «б» һәм «в» пунктчалары, 4 пункты, 5 пунктының «а» пунктчасы, 6 пунктының «а» пунктчасы, «б» пунктчасындагы икенче абзацы һәм «в» пунктчасы, 7, 15, 17 һәм 18 пунктлары 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасы, 2 пунктының «а» пунктчасы, 3 пункты, 5 пунктының «б» пунктчасы, 6 пунктының «б» пунктчасындагы өченче абзацы, 12 пунктының «а» пунктчасы, 13, 14, 16, 21 һәм 24 пунктлары 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 8, 11, 19 һәм 20 пунктлары 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

5. Әлеге Законның 1 статьясындагы 23 пункты 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

6. Татарстан Республикасы Экология кодексының 36 статьясы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) билгеләнгән тәртиптә аттестация үткән экспертларны дәүләт экология экспертизасын уздыруга җәлеп итү өлешендә 2025 елның 1 сентябреннән кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 51-ТРЗ